**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

« 18 » 04 2025 ел                                        Яр Чаллы                                        № 1278

«Тукай муниципаль районында үзәкләштерелгән бухгалтерия җитәкчеләре һәм белгечләре хезмәтенә түләү оештыру һәм шартлары турында» Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 22 апрельдәге 1473 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Хезмәткә түләү һәм премияләр бирү системасын үзгәртү кирәклегенә бәйле рәвештә

## КАРАР БИРӘ:

1. Тукай муниципаль районында үзәкләштерелгән бухгалтерия җитәкчеләре һәм белгечләре хезмәтенә түләү оештыру һәм шартлары турында нигезләмәгә (Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең 2023 елның 25 гыйнварендәге 214 номерлы, 2024 елның 8 маендагы 1147 номерлы, 2024 елның 2 декабрендәге 5408 номерлы карарлар белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктның 5 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

отпускка ике вазыйфаи окладтан артмаган күләмдә матди ярдәм календарь ел дәвамында түләнергә мөмкин,

өстәмә матди ярдәм түбәндәге очракта түләнә:

- юбилей даталары (50 яшьтән башлап һәм аннан соңгы һәр 5 ел саен), никахлашу, бала туу (уллыкка алу, кызлыкка алу);
- катлаулы формада уза торган авыру,
- якыннарының (ата-аналарының, балаларының, тормыш иптәшенең вафат булуы),
- табигый бәла-каза яки гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәсендә мөлкәтнең югалуы яки зыян күрүе.

4 пунктның 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

район бюджетына өстәмә керем чыганаклары булганда һәм эш бирүче карары буенча премияләр ай саен, квартал саен, ел саен эш нәтиҗәләре буенча, үзәкнең бурычларын һәм функцияләрен үтәүне тәэмин итүне, вазыйфаи инструкцияләрне үтәүне исәпкә алып, шулай ук һөнәри бәйрәмнәргә, бәйрәм даталарына һәм башкаларга түләнергә мөмкин.

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2025 елның 1 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе К.Р. Нәҗмиев